КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 декабрь г.Казань № 1639

Сәнәгать технопарклары идарәче компанияләренең электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзүгә, үстерүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә документаль расланган чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү яисә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең ««Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы һәм «Электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яисә) модернизацияләү проектларына дәүләт ярдәменә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 19 сентябрендәге 1659 номерлы карарлары нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1043 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы

дәүләт программасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Сәнәгать технопарклары идарәче компанияләренең электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзүгә, үстерүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә документаль расланган чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү яисә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин